КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 26 гыйнвар г.Казань № 49

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләрен раслау турында» 2002 ел, 18 июль, 426 нчы карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2015 ел, 19 май, 356 нчы; 2016 ел, 16 июнь, 408 нче; 2017 ел, 28 ноябрь, 920 нче; 2018 ел, 14 март, 152 нче; 2018 ел, 17 декабрь, 1153 нче; 2020 ел, 22 июль, 617 нче; 2022 ел, 23 июнь, 602 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Республика башкарма хакимият органнарының норматив хокукый актларын әзерләү, аларны дәүләт теркәвенә алу һәм бастырып чыгару кагыйдәләренә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Дәүләт серенә ия белешмә, конфиденциаль характердагы белешмә, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә игълан ителмәскә тиешле башка белешмә бирелгән норматив хокукый актны дәүләт теркәвенә алу турында хәбәрнамә кәгазь чыганакта җибәрелә, аңа мондый норматив

хокукый актның кәгазь чыганактагы төп нөсхәсе теркәлә, анда дәүләт теркәвенә алу датасы һәм теркәү номеры күрсәтелә, теркәү штампы сугыла.»;

3.3 пунктның беренче абзацына түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә:

«Дәүләт серенә ия белешмә, конфиденциаль характердагы белешмә, Россия Федерациясе законнары һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә игълан ителмәскә тиешле башка белешмә булган норматив хокукый актларның текстлары бирелми.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин